КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 март г.Казань № 251

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 910 нчы карары белән расланган Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 910 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1363 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Министрлыкның төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары:

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – министр);

Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары);

халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте чараларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы;

халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте чараларын гамәлгә ашыру бүлеге төп киңәшчесе.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Контрольдә тотыла торган затларның эшчәнлеген билгеле бер риск категориясенә кертү турындагы карар ел саен, агымдагы елның 15 августына кадәр, контрольдә тотыла торган затларның эшчәнлеген билгеле бер риск категорияләренә кертү критерийлары нигезендә, аларны киләсе календарь елда куллану өчен, Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин